Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге
Пановка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

1 декабрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегенең Пановка торак пунктында 2021 елның 1 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 470 (дүрт йөз җитмеш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 243 (ике йөз кырык өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 243 (ике йөз кырык өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2022 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- Пановка торак пункты территориясен төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев